ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.10.2015**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2081**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукы турында» 2015 елның 06 августындагы 1642 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 06 августындагы«Зеленодольск муниципаль районында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү тәртибе турында» 1642 номерлы карарындагы 3 нче кушымтада җибәрелгән техник хатага бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы  Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 06 августындагы «Зеленодольск муниципаль районында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү тәртибе турында» 1642 номерлы карарына, 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) раслап , үзгәреш кертергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукы турында» 2015 елның 06 августындагы 1642 номерлы карарының 3 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.
3. ЗМР Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына ТР хокукый мәгълүмат сайтында pravo.tatarstan.ru һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru/урнаштыруны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче С.Г. Егоров

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
08.10.2015 № 2081
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәсе буенча түләүнең старт (башлангыч) күләмен исәпләү тәртибе**

Реклама конструкциясен урнаштыруның **(Т) старт (башлангыч) бәясе күләме, 1 ел эчендә хакы чыгарулуны исәпкә алып, түбәндәгечә исәпләнә:**

**Т=Р х П х К1 х К2 х 12 ай**,

биредә
Р - реклама конструкциясенең мәгълүмат кырының 1 квадрат метрын сатуның уртача базар бәясе (үлчәү берәмлеге - аена сум);

П – реклама конструкциясенең мәгълүмат кырларының гомуми мәйданы (үлчәү берәмлеге-квадрат метр);

К1 - йөкләнеш коэффициенты. Реклама конструкциясендә реклама бирүчеләрнең реклама мәгълүматы урнаштырылмаган чорларны исәпкә алына торган түбәнәйтелгән коэффициенты, К1=0,7;

К2 - рентабельлек коэффициенты. Реклама конструкциясе милекчесенең кереме күләмен исәпкә ала торган түбәнәйтелгән коэффициенты, К2=0,7.

К3 - зона коэффициенты. Реклама конструкцияләрен урнаштыру дәрәҗәсе принциплары буенча Зеленодольск муниципаль районы 5 зонага бүленә:
**1 нче зона** - Зеленодольск шәһәре: Башкала, Комаров, Королев, Октябрь, Иван Заикин, Ленин, Татарстан, Карл Маркс, Энгельс, Гоголь урамнары.
**2 нче зона** - Зеленодольск шәһәре: калган барлык урамнар.
**3 нче зона** - Осиново авыл җирлеге.
**4 нче зона** - Октябрь авыл җирлеге.
**5 нче зона** - башка калган җирлекләр.

К3 зонасы коэффициенты түбәндәге күрсәткечләрне кабул итә:
1,0 - 1 һәм 2 зоналары;
0,5 - 3 һәм 4 зоналары;
0,25 - 5 зона»